КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 20 март г.Казань № 210

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүдән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүдән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2009 елда Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджетында җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүдән бертигез файдалануны тәэмин итү өчен каралган субсидияләрне һәм субвенцияләрне бирү турында» 2009 ел, 10 март, 134 нче карары белән расланган 2010 елда Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджетында җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүдән бертигез файдалануны тәэмин итү өчен каралган субвенцияләрне бирү тәртибе үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 20 март, 210 нчы
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүдән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге ТРЗ-123 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү өлкәсендә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр (алга таба шул ук эзлеклелектә – дәүләт вәкаләтләре, субвенцияләр) бирү кагыйдәләрен билгели.

2. Субвенцияләр бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлык) субвенцияләр белән баш эш итүче буларак билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 8енә кадәр, Министрлыкка Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 апрель, 161 нче карары белән күздә тотылган Транспорт оешмаларына транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет буенча гражданнарга транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле чыгымнарына Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсацияләр күләмен хисаплап чыгару методикасы нигезендә төзелгән исәп-хисаплар-белешмә кәгазьләре (алга таба – исәп-хисаплар-белешмә кәгазьләре) һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 23 июль, б-1416 нчы боерыгы белән расланган форма буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар кертә.

4. Министрлык ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, субвенцияләрнең бирелергә тиешле күләмнәре турындагы ирекле рәвеш-

тә язылган заявканы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына (алга таба – Финанс министрлыгы) кертә.

5. Субвенцияләр Министрлыкның Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетына субвенцияләр кергәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Министрлык тарафыннан аларның кергәнен исәпкә алу һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында бүлү өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә Федераль казначылыкның территориаль органнарына ачылган счетларга күчерелә.

6. Агымдагы елның декабре өчен субвенцияләр Министрлык тарафыннан агымдагы финанс елының 25 декабренә кадәр бу Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән һәм тапшырылган исәп-хисаплар-белешмә кәгазьләре нигезендә агымдагы финанс елының ноябре өчен бирелергә тиешле субвенцияләр күләмендә күчерелә.

Бу Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән агымдагы финанс елының декабре өчен хисаплар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан Министрлыкка кертелә.

Агымдагы елның декабренә бирелгән субвенцияләр бу ай өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына бирелергә тиешле субвенцияләрдән арткан очракта, артып киткән сумма агымдагы елның 31 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

7. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары субвенцияләрнең максатчан файдаланылмавы һәм бу Тәртипнең 3 нче пункты нигезендә тапшырыла торган мәгълүматларның дөрес булмавы өчен җавап бирә.

8. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан субвенцияләр максатчан файдаланылмаган очракта, тиешле акча Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

9. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан субвенцияләрнең сарыф ителүен һәм субвенцияләрне максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлыкка йөкләнә.

10. Агымдагы финанс елыннан соң килә торган финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган субвенцияләр агымдагы финанс елыннан соң килә торган финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

Субвенцияләрнең файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемenә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләрне үтәп, Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә түләтелергә тиеш.

11. Әгәр дә Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.6 статьясы нигезендә тиешле елга Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары арасында бүлен-

мәгән субвенцияләрнең бер өлеше (алга таба – резерв) каралган булса, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының әлеге акчага өстәмә ихтыяҗ булу турындагы мөрәҗәгатьләре булганда Министрлык әлеге акчаны бүлү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә хокуклы.

Әлеге акча Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карта буенча юл йөрүләрнең факттагы уртача айлык саны, юл йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторлары мәгълүматлары буенча башкарылган пассажирлар йөртелгән километрларның уртача айлык саны артуга һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан бу Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән исәп-хисаплар-белешмә кәгазьләре әзерләнгәндә кулланыла торган тарифлар үзгәрүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән субвенцияләргә өстәмә ихтыяҗ күләмендә Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетлары арасында бүленә.

Бүленгән акча бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга җибәрелә.

Субвенцияләр җитәрлек булмаганда, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, агымдагы елның касса операцияләре тәмамлану вакытларын исәпкә алып, Министрлыкка, соратып алына торган акча күләмен нигезләп, резервтан өстәмә акча бүлеп бирү турында мөрәҗәгать җибәрә.

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына резерв акчасын бүлеп бирү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары нигез булып тора.